**СОВЕТ**
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Кооперативная, д. 22, с.Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты
авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Советы карары**

**« 01 » июль 2024г** **№ 120**

**«Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм Утар-Аты авыл җирлегенең аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында» 2024 елның 11 июньдәге 118 номерлы Утар-Аты авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.**

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасында Муниципаль хезмәт кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 06 майдагы 300 номерлы карары белән,Татарстан Республикасында депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге уставы нигезендә, Утар-Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

2. «Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм Утар-Аты авыл җирлегенең аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында»2024 елның 11 июньдәге 118 номерлы Утар-Аты авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 Пункт Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларга хезмәт хакы түләү турында Нигезләмәне (2 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Утар-Аты авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең вазыйфаи оклады күләмен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициенты түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Коэффициент |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе | 1,37 |
| Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре) | 1,33 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,11 |
| 1 категорияле белгеч<br>2 категорияле белгеч<br>белгеч | 1,00 |

3. Әлеге карар 2024 елның 01 июленнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) Җирлекләр бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева

СОВЕТ УТАР-АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609012621